| | | |
|---|---|---|
| **ГОСУДАРСТВЕННАЯ ИНСПЕКЦИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ОБЕСПЕЧЕНИЮ ГОСУДАРСТВЕННОГО КОНТРОЛЯ ЗА ПРОИЗВОДСТВОМ, ОБОРОТОМ И КАЧЕСТВОМ ЭТИЛОВОГО СПИРТА, АЛКОГОЛЬНОЙ ПРОДУКЦИИ И ЗАЩИТЕ ПРАВ ПОТРЕБИТЕЛЕЙ**<br>(Госалкогольинспекция Республики Татарстан) | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ЭТИЛ СПИРТЫ һӘМ АЛКОГОЛЬЛЕ ПРОДУКЦИЯ ҖИТЕШТЕРҮНЕ, ӘЙЛӘНЕШТӘ ЙӨРТҮНЕ, СЫЙФАТЫН ДӘҮЛӘТ ТИКШЕРҮЕН ТӘЭМИН ИТҮ һӘМ КУЛЛАНУЧЫЛАР ХОКУКЛАРЫН ЯКЛАУ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ ИНСПЕКЦИЯСЕ**<br>(Татарстан Республикасы дәүләт алкоголь инспекциясе) |

# ПРИКАЗ

01.02.2017 № 12–07 / 7

Казан ш.

Татарстан Республикасы территориясендә алкогольле продукцияне ваклап сатуны һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

“Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 27 июль, 2010 ел, № 210-ФЗ Федераль закон һәм “Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” 02.11.2010 ел, № 880 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы территориясендә алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү процедурасын камилләштерү максатыннан чыгып, боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы территориясендә алкогольле продукцияне ваклап сатуны һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын (кушымта итеп бирелә) расларга.

2. Административ һәм суд практикасы бүлегенә Б.Г. Эйдинов бу боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. “Татарстан Республикасы территориясендә алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 04.07.2012 ел, № 202 Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Ж.Ю. Әхмәтханов

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең
01 февраль, 2018 ел, № 12-07/7
боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы территориясендә алкогольле продукцияне ваклап сатуны һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Регламент Татарстан Республикасы территориясендә алкогольле продукцияне ваклап сатуны һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү (авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре тарафыннан шәраб, күбекле шәрабне (шампан шәрабе) ваклап сатуны лицензияләүдән тыш) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба – дәүләт хезмәте), алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия, җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия бирүне, лицензиянең гамәлдә булу срогын озайту, лицензияне яңадан рәсмиләштерү, лицензиянең гамәлдә булуын яңарту һәм туктатып торуны кертеп (алга таба – лицензия), стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәте алучылар – юридик затлар (алга таба – мөрәҗәгать итүче).

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне, сыйфатын дәүләт тикшерүен тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе (алга таба – ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе) һәм аның территориаль органнары тарафыннан күрсәтелә

1.3.1. ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең урнашу урыны: 420107, Казан ш., Һ.Такташ ур.,94 й., кабул итү бүлмәсе телефоны: (843) 278-92-00, 278-91-92.

Территориаль органнар турында мәгълүматлар (атамасы, адресы, үзләре хезмәт күрсәтә торган муниципаль берәмлекләр, телефоны) 15 нче кушымтада күрсәтелгән.

ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең һәм Казан территориаль органының эш графигы: шимбә һәм якшәмбедән тыш, көн саен. Дүшәмбе - пәнҗешәмбе 8.30 сәгатьтән 17.30 сәгатькәчә, җомга - 8.00 сәгатьтән 15.45 сәгатькәчә. Төшке аш вакыты: 12.00 сәгатьтән 12.45 сәгатькәчә. Бәйрәм алды көннәрендә эш сәгате вакыты 1 сәгатькә кыскара.

ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе территориаль органнарының эш графигы: шимбә һәм якшәмбедән тыш, көн саен. Дүшәмбе - пәнҗешәмбе 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькәчә, җомга - 8.00 сәгатьтән 15.45 сәгатькәчә. Төшке аш вакыты: 12.00 сәгатьтән 12.45 сәгатькәчә. Бәйрәм алды көннәрендә эш сәгате вакыты 1 сәгатькә кыскара.

Документларны кабул итү вакыты: дүшәмбе, чәршәмбе, җомга – 9:00 сәгатьтән 12:00 сәгатькәчә, сишәмбе, пәнҗешәмбе – 13:00 сәгатьтән 16:00 сәгатькәчә.

ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенә һәм Казан территориаль органына керү электрон пропусктан һәм (яки) шәхесне раслаучы документтан файдаланып хәл ителә.

ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең башка территориаль органанрына керү – ирекле.

1.3.2. ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтлары адреслары: http://gosalcogol.tatar.ru, Электрон почта адресы: cla@tatalc.ru.

1.3.3.Дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүматлар алынырга мөмкин:

1) ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе бинасында урнашкан дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүматлардан торучы мәгълүмати стендлар аша.

Мәгълүмати стендларда урнаштырылган мәгълүматлар Татарстан Республикасы территориясендә алкогольле продукцияне ваклап сатуны һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең бу административ регламентының 1.1, 1.3.1, 1.4, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) (алга таба – Регламент) дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүматларны үз эченә ала;

2) «Интернет» челтәре аша:

ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең рәсми сайтында (https:// gosalcogol.tatar.ru);

Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында (http://uslugi.tatar.ru/);

Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) күрсәтүнең бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

3) ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенә телдән мөрәҗәгать итеп (шәхсән яки телефон аша);

4) ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенә язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать итеп.

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге законнар һәм норматив-хокукый актлар нигезендә хәл ителә:

Россия Федерациясе Салым кодексы (икенче өлеше) (алга таба – РФ СК) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы”, 2000, № 32, ст. 3340);

“Этил спиртын, алкогольле һәм спиртлы продукция житештерүне һәм әйләнешен дәүләти җайга салу һәм алкогольле продукция куллануны (эчү) чикләү турында” 22 ноябрь, 1995 ел, № 171- ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 1995, № 48, ст. 4553кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Электрон имза турында” 6 апрель, 2011 ел, № 63-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 63-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2011, № 15, ст. 2036, кертелгән үзгәрешләрдән чыгып);

“Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында” 7 май, 2012 ел, № 601 Россия Федерациясе Президенты Указы (алга таба – № 601 РФ Президенты Указы) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2012, № 19, ст. 2338, кертелгән үзгәрешләрдән чыгып);

“Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне, сыйфатын дәүләт тикшерүен тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе мәсьәләләре” 05.08.2005 ел, № 391 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне, сыйфатын дәүләт тикшерүен тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе турында нигезләмә (алга таба – ТР МК 05.08.2005 ел, №391 карары белән расланган Нигезләмә) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары җыентыгы, 10.08.2005, № 30, ст. 0725, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 02.11.2010 ел, №880 карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе (алга таба – №880 ТР МК карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары җыентыгы, 08.12.2010 ел, № 46, ст. 2144; 20.12.2011 ел, №48, ст.2612; 25.05.2012 ел, №40, ст.1252, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Алкогольле продукцияне ваклап сатуны хәл итүче оешмаларның түләнгән устав капиталының минималь күләмен билгеләү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының һәм карарлары нигезләмәләренең үз көчен югалтуын тану турында” 15.03.2014 ел, № 161 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – №161 ТР МК карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары җыентыгы, 25.03.2014 ел, 20.05.2014 ел, №37, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып;

“Устав капиталын түләүне раслаучы документлар турында” 13.12.2005 ел, № ШТ-6-07/1045 Россия Федерациясе Федераль салым хезмәте хаты (алга таба – РФ ФСХ хаты) («Учет. Налоги. Право» газетасына кушымта - «Официальные документы» 10.01.2006 ел, №1).

1.5. Бу Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла: алкогольле продукция – әзер продукция күләмендә этил спирты микъдары 0,5 проценттан артыграк булган, азык-төлек чималыннан һәм (яки) спиртлы азык-төлек продукциясеннән җитештерелгән этил спиртыннан файдаланып яки аннан файдаланмыйча җитештерелгән азык-төлек продукциясе, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән исемлек нигезендәге азык-төлек продукциясеннән тыш. Алкогольле продукция спиртлы эчемлекләр (шул

исәптән аракы, коньяк), шәраб, җимеш шәрабе, ликерлы шәраб, күбекле шәраб (шампан шәрабе), шәраб эчемлекләре кебек төрләргә бүленә);

алкогольле продукцияне ваклап сату – алкогольле продукцияне сатып алу һәм саклауга, алга таба аны сатып алучыларга, җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтүне кертеп, эшмәкәрлек эшчәнлегенә бәйле булмаган шәхсән, гаиләдә, йортта куллану өчен сатып җибәрүгә бәйле эшчәнлек төре;

лицензияләүче орган – ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе һәм аның территориаль органнары;

лицензия – лицензияләүче орган тарафыннан юридик затка бирелгән, лицензия таләпләрен һәм шартларын мәҗбүри рәвештә үтәүне күздә тотып, алкогольле продукцияне ваклап сатуны хәл кылу өчен бирелгән махсус рөхсәт;

лицензиягә кушымта – лицензияләүче орган тарафыннан конкрет лицензия кысаларында һәр лицензияләү объектына бирелә торган документ;

лицензия таләпләре һәм шартлары – эшчәнлекнең лицензияләнелә торган төрен хәл иткәндә лицензиат тарафыннан мәҗбүри төстә үтәлергә тиешле Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында билгеләнгән таләпләр һәм шартлар тупланмасы;

лицензиягә дәгъва кылучы – лицензияләүче органга алкогольле продукцияне ваклап сату хокукын алу өчен лицензия бирү турында гариза белән мөрәҗәгать иткән юридик зат;

лицензиат – алкогольле продукцияне ваклап сату өчен лицензиягә ия булган юридик зат;

мөрәҗәгать итүче – дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап лицензияләүче органга мөрәҗәгать иткән лицензиягә дәгъва кылучы (лицензиат);

гариза – №210-ФЗ Федераль законның 2 статьясындагы 1 пунктында күздә тотылган дәүләт хезмәте күрсәтү турында запрос. Гаризалар формалары бу Регламентка 5 нче, 6 нчы, 7 нче, 8 нче кушымталарда китерелгән.

лицензияләр реестры – Татарстан Республикасы территориясендә бирелгән, гамәлдә булу срогы озайтылган, яңадан рәсмиләштерелгән, гамәлдә булуы туктатып торылган, гамәлдә булуы яңартылган, гамәлдә булуы туктатылган һәм юкка чыгарылган лицензияләр турында мәгълүматлардан торган мәгълүматлар тупланмасы;

техник хата – лицензия һәм аңа кушымталар әзерләгәндә лицензияләүче орган тарафыннан җибәрелгән техник хата (сүз хатасы, хәреф хатасы һ.б.);

дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күп функцияле үзәгенең ерактагы эш урыны – муниципаль районнарның авыл җирлекләрендә мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү һәм документлар бирү, аларга консультацияләр бирү өчен “тәрәзә”.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләп атамасы | Стандартка таләпләрнең эчтәлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү атамасы | Татарстан Республикасы территориясендә алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү | № 171-ФЗ Федераль законның 18 ст. 2 п.; |
| 2.2. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче башкарма хакимият органы атамасы | Татарстан Республикасының Этил спирты һәм алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне, сыйфатын дәүләт тикшерүен тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе | ТР МК 05.08.2005 ел,№391 карары белән расланган Нигезләмәнең 1.1, 3.3 п.п. |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | 1) кушымта белән, алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия бирү турында уведомление һәм алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия ;<br>2) кушымта белән, җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия бирү турында уведомление һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия;<br>3) озайту турында билге белән, лицензиянең гамәлдә булу срогын озайту турында уведомление һәм алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия;<br>4) озайту турында билге белән, җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензиянең гамәлдә булу срогын озайту турында уведомление һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия<br>5) лицензияне яңадан рәсмиләштерү турында уведомление һәм лицензиягә яңадан рәсмиләштерелгән кушымталар; | № 171-ФЗ Федераль законның 6 ст. 1п., 18 ст. 10 п., 19 ст. 11п., 12,17 п., 20 ст 1,2п. |

| | | |
|---|---|---|
| | 6) лицензиянең гамәлдә булуын яңарту турында уведомление;<br>7) алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия бирүдән баш тарту турында уведомление;<br>8) җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия бирүдән баш тарту турында уведомление;<br>9) лицензиянең гамәлдә булу срогын озайтудан баш тарту турында уведомление;<br>10) лицензияне яңадан рәсмиләштерүдән баш тарту турында уведомление;<br>11) лицензиянең гамәлдә булуын яңартудан баш тарту турында уведомление;<br>12) лицензиатның гаризасы нигезендә лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында уведомление;<br>13) кире алу турында гариза нигезендә гаризаны карап тикшерү процедурасын туктату турында уведомление. | |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору срогы, Россия Федерациясе законында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта | Лицензия бирүне, озайту, аны яңадан рәсмиләштерүне үз эченә алган дәүләт хезмәте күрсәтү срогы, кирәкле барлык документлар белән, гаризаны теркәүгә алганнан соң 15 көннән дә артмый.<br>Өстәмә экспертиза үткәрү зарурилыгы очрагында, гаризаны карап тикшерү срогын озайту турында оешмага хәбәр итеп, әлеге срок аны үткәрү чорына озайтыла, әмма күп дигәндә 30 календарь көненә генә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору срогы күздә тотылмаган.<br>Лицензиаттан лицензиясенең гамәлдә булуын туктатып торуга китергән хәлләрнең юкка чыгарылуы турында гариза алынганнан соң 14 календарь көне эчендә лицензиянең гамәлдә булуын яңарту яки аның гамәлдә булуын яңартудан баш тарту | № 171-ФЗ Федераль законның 19 ст. 7 п.;<br><br>№ 171-ФЗ Федераль законның 20 ст. 1 п.; |

| | | |
|---|---|---|
| | һәм лицензияне юкка чыгару турында гариза белән судка мөрәҗәгать итү турында карар кабул ителә.<br>Лицензиатның гаризасы нигезендә лицензиянең гамәлдә булуын туктату буенча дәүләт хезмәте күрсәтү срогы лицензия кушып бирелгән гариза теркәүгә алынганнан соң 10 эш көненнән артмый. | |
| 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып торган хезмәтләрне күрсәтү өчен, закон яки башка норматив-хокукый актлар нигезендә кирәкле, гариза бирүче тапшырырга тиешле документларның тулы исемлеге, гариза бирүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе | Алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия алу өчен, №1 кушымта нигезендә, документлар тапшырыла.<br>Җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия алу өчен, №2 кушымта нигезендә, документлар тапшырыла.<br>Лицензиянең гамәлдә булу срогын озайту өчен, №3 кушымта нигезендә, документлар тапшырыла.<br>Лицензияне яңадан рәсмиләштерү өчен, №4 кушымта нигезендә, документлар тапшырыла.<br>Лицензиат лицензиясенең гамәлдә булуын яңарту өчен лицензияләүче органга , нигезләү документлары белән бергә, лицензиясенең гамәлдә булуын туктатып торуга китергән хәлләрне юкка чыгару турында гариза тапшыра. Лицензиянең гамәлдә булуын яңарту турында гаризада күрсәтелә: оешма атамасы һәм оештыру-хокукый формасы, ИНН, лицензиянең реестр һәм теркәү номеры, лицензияне бирү датасы; лицензиянең гамәлдә булуын туктатып торуга китергән хәлләр һәм әлеге хәлләрне юкка чыгару ысулы.<br>Лицензиат лицензиясенең гамәлдә булуын туктату өчен, №8 кушымта нигезендә, документлар тапшыра.<br>Мөрәҗәгать итүче гаризасын һәм аңа кушып бирелә торган документларны, кабул итү сәгатьләрендә мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә, кәгазьдә тапшырырга мөмкин.<br>Мөрәҗәгать итүче гаризасын һәм документларын шулай ук гомум мөмкинлекле мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, | № 171-ФЗ Федераль законның 19 ст. 3.2, 3.2-1, 3.2-2 п.;<br>№210-ФЗ Федераль закон;<br>№63-ФЗ Федераль закон;<br>№161 ТР МК карарының 1 п.<br>РФ ФСХ хаты |

| | | |
|---|---|---|
| | шул исәптән «Интернет» челтәре аша, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документлар рәвешендә дә тапшырырга мөмкин.<br>Дәүләт хезмәте алу өчен гариза бланкы ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең рәсми сайтына урнаштырылган. | |
| 2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив-хокукый актлар нигезендә кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булып, мөрәҗәгать итүче тапшыруга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук гариза бирүчеләр тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар алар карамагында булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яки оешма | Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен түбәндәге органнар карамагындагы түбәндәге документлар (мәгълүматлар) кирәк:<br>а) Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсеннән – дәүләт пошлинасын түләү турында мәгълүматлар;<br>б) Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсеннән – Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан мәгълүматлар;<br>в) Дәүлә теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән – Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрыннан мәгълүматлар;<br>г) Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсеннән – техник мөмкинлек булганда, эшмәкәрлек эшчәнлегенең аерым төрләрен хәл кылуны башлап җибәрү (Россия буенча) турында уведомлениеләр реестрыннан мәгълүматлар<br>Мөрәҗәгать итүче бу пунктта күрсәтелгән мәгълүматлардан торган документларны, шул исәптән, мөмкинлек булганда электрон рәвештә, тапшыруга хокуклы.<br>Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтеп үтелгән мәгълүматларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуга нигез булып тора алмый.<br>Мөрәҗәгать итүче тапшыруга хокуклы документларны алу ысуллары һәм тәртибе бу Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән.<br>Мөрәҗәгать итүчедән дәүләт органнары, җирле үзидарә | №171-ФЗ Федераль законның 19 ст.3.2, 3.2-2 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | органнары һәм башка оешмалар карамагындагы югарыда санап үтелгән документларны таләп итү тыела. | |
| 2.7. Норматив-хокукый актларда күздә тотылган очракларда, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен аларның килештерүләре (дәүләт хезмәте күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан башкарыла) таләп итеlә торган дәүләт хакимияте органнары һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне килештерү таләп ителми. | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләрнең тулы исемлеге | Фәкать түбәндәге очракларда гына документларны кабул итүдән баш тарту мөмкин:<br>- гаризаны вәкаләте булмаган зат тапшырганда;<br>- тапшырылган документларда чистарту-бетерү, сызу-бозулар, аңлатылмаган төзәтүләр булганда, шулай ук документлар карандаш белән тутырылганда, документларга эчтәлеген төгәл генә аңлап булмаслык дәрәҗәдә зыян килгәндә;<br>- № 63-ФЗ һәм №210-ФЗ Федераль законнар нигезендә электрон имза белән имзаланмаган (расланмаган) электрон рәвештәге гариза һәм документлар (күчермәләре) тапшырганда. | №210-ФЗ Федераль закон;<br>№63-ФЗ Федераль закон |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки аннан баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Баш тартуга нигезләр булып тора:<br>- тапшырылган документларда дөрес булмаган, ялган, шулай ук тулы булмаган мәгълүматлар күрсәтелгәндә – мондый тулы булмаган мәгълүмат мөрәҗәгать итүченең лицензия таләпләренә туры килүен билгеләү мөмкинлеге бирмәгән очракта;<br>- мөрәҗәгать итүченең айның беренче числосына һәм | №171-ФЗ Федераль законның 19 ст. 9 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | лицензия бирү турында гаризасының лицензияләүче органга керү датасына түләнмәгән салымнар, җыемнар түләү, Салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законын бозган өчен пенялар һәм штрафлар түләү буенча түләнелмәгән бурычы (лицензияләүче орган запросы буенча гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән, шул исәптән "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдалану нигезендә алынган электрон документ рәвешендә салым органы белешмәсе белән расланган) булганда;<br>- мөрәҗәгать итүченең лицензияләүче органга лицензия бирү турында гаризасын тапшыру датасына Административ хокук бозу турында Россия Федерациясе кодексында күздә тотылган этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерү һәм әйләнеше өлкәсендә кылынган хокук бозулар өчен билгеләнеп, тиешле срокта түләнмәгән штрафының булуы;<br>- мөрәҗәгать итүченең № 171-ФЗ Федераль законның 2, 8, 9, 10.1, 11, 14.1, 16, 19, 20, 25 һәм 26 статьялары нигезләмәләре буенча билгеләнгән лицензия таләпләренә туры килмәве.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү срокларын туктатып торуга нигезләр билгеләнмәгән. | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен дәүләт пошлинасы яки башка төрле түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Алкогольле продукцияне ваклап сатуга һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия лицензия бирү, гамәлдә булу вакытын озайту һәм лицензияне яңадан рәсмиләштерү өчен түбәндәге күләмнәрдә дәүләт пошлинасы алына:<br>- алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия тапшыру (бирү) – лицензиянең гамәлдә булу срогының һәр елы өчен 65 000 сум;<br>- җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия тапшыру (бирү) - | РФ СК 333.33 ст.1 п. 94 пп. |

| | | |
|---|---|---|
| | лицензиянең гамәлдә булу срогының һәр елы өчен 65 000 сум;<br><br>- лицензиянең гамәлдә булу срогын озайту – алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия, җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия бирү өчен билгеләнгән күләмдә;<br>- юридик зат үзгәртеп оештырылганда (кушылу яки үзгәртелү рәвешендә юридик затларның үзгәртеп оештырылуыннан тыш һәм үзгәртеп оештырылган юридик затларның хокукый дәвамчысының дәүләт теркәвенә алу датасына юридик затның һәркайсы шул бер үк эшчәнлек төрен хәл кылу өчен лицензиягә ия булудан тыш) лицензияне яңадан рәсмиләштерү – лицензиянең тиешле төрен бирү өчен билгеләнгән күләмдә;<br>- кушылу яки үзгәртелү рәвешендә юридик затлар үзгәртеп оештырылганда һәм үзгәртеп оештырылган юридик затларның хокукый дәвамчысының дәүләт теркәвенә алу датасына юридик затның һәркайсы шул бер үк эшчәнлек төрен хәл кылу өчен лицензиягә ия булганда лицензияне яңадан рәсмиләштерү – 3 500 сум;<br>- юридик зат атамасы үзгәртелүгә (үзгәртеп оештырылмыйча гына), аның урнашу урыны яки лицензиясендә күрсәтелгән эшчәнлекне хәл кылу урыны яисә лицензиядә күрсәтелгән башка мәгълүматлар үзгәртелүгә бәйле рәвештә, шулай ук лицензияне югалтуга бәйле рәвештә лицензияне яңадан рәсмиләштерү - 3 500 сум.<br>Оешмаларга алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияләр бирү, озайту һәм аларны яңадан рәсмиләштерү өчен дәүләт пошлинасы түләүгә счет реквизитлары:<br>Расчетный счет – 40101810800000010001<br>БИК банка – 049205001<br>Банк получателя – Отделение-НБ Республика Татарстан | |

| | | |
|---|---|---|
| | ИНН 1654025044 КПП 165901001<br>Получатель – УФК по РТ (Государственная инспекция Республики Татарстан по обеспечению государственного контроля за производством, оборотом и качеством этилового спирта, алкогольной продукции и защите прав потребителей)<br>Бюджет классификациясе коды: 750 1 08 07082 01 1000 110<br>Түләү билгеләнеше (лицензия бирү яки озайту өчен): Алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияләр бирү (озайту) өчен дәүләт пошлинасы”.<br>Түләү билгеләнеше(лицензияне яңадан рәсмиләштерү өчен): Алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияләрне яңадан рәсмиләштерү өчен дәүләт пошлинасы”.<br>ОКТМО оешма-түләүченең теркәлү урыны буенча күрсәтелә.<br>ОКТМО Казан ш. 92 701 000<br>Чистай ш. 92 659 101<br>Түбән Кама ш. 92 644 101<br>Чаллы ш. 92 730 000<br>Арча ш. 92 612 151<br>Зеленодол ш. 92 628 101<br>Әлмәт ш. 92 608 101 | |
| 2.11.Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып торган хезмәтләргә түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре, мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны кертеп | Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми. | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать | Лицензиягә дәгъва кылучы (лицензиат) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм (яки) дәүләт хезмәте | N 601 РФ Президенты Указы 1 п. |

| | | |
|---|---|---|
| тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы | нәтиҗәсен алганда чиратта көтү вакыты 15 минуттан артмаска тиеш .<br><br>Дәүләт хезмәте алучыларның аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән. | |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында запросын, шул исәптән электрон рәвештә, теркәү срогы | Гариза кергән көнне.<br>Ял көннәрендә яки эш көне булмаган бәйрәм көннәрендә электрон рәвештә гариза кергән очракта аны теркәү ял көненнән соң яки эш көне булмаган бәйрәм көненнән соң килүче беренче эш көнендә хәл ителә. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, карата таләпләр | Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документлар рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель һәм мәгълүмати стендлар белән җиһазландырылган биналар һәм бүлмәләрдә башкарыла.<br>Инвалидларның хезмәт күрсәтү урынына комачаулыкларсыз үтү, шул исәптән объектларга комачаулыкларсыз керү һәм алардан чыгу, шулай ук хезмәт күрсәтү урынына барып җиту максатыннан объектта мөстәкыйль хәрәкәтләнү мөмкинлеге тудырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиаль мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарга, шул исәптән инвалидларның чикле мөмкинлекләреннән чыгып, урнаштырыла. | №391 ТР МК карары белән расланган нигезләмә |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең мөмкинлек һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә, гариза бирүченең вазыйфаи затлар белән аралашулары саны һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлек күрсәткечләре булып тора:<br>ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе бинасының җәмәгать транспорты йөри торган зонада урнашкан булуы;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен билгеләнгән бүлмәләргә инвалидларның үтү мөмкинлеге тудырылган булу;<br>белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү өчен билгеләнгән бүлмәләрнең кирәкле | N880 ТР МК карарының 2.4 п.<br>N601 РФ Президенты Указының 1 п. |

| | | |
|---|---|---|
| хезмәтен дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәктә, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннарында алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүматны алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдаланып | санда булуы;<br>Мәгълүмати стендларда, “Интернет” челтәрендә, ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, сроклары турында тулы мәгълүматларның булуы;<br>электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;<br>мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон рәвештә дәүләт хезмәтләрен алу мөмкинлеге;<br>Инвалидларга башка затлар белән бертигез рәвештә хезмәт күрсәтүләр алуга комачаулардай, инвалидларны бүлмәләргә үтү мөмкинлеге белән тәэмин итүгә бәйле булмаган бүтән киртәләрне узуга ярдәм итү.<br><br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып тора:<br>документларны кабул итү һәм карап тикшерү срокларын үтәү;<br>дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу срогын үтәү;<br>дәүләт хезмәте күрсәтүчеләр тарафыннан Регламентны бозуга нигезле шикаятьләрнең булмавы;<br>мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче белгечләр белән берлектә эшләве саны:<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны тапшырганда, турыдан-туры күп дигәндә бер тапкыр (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша, шул исәптән электрон почта аша җибәргәндә – күп дигәндә бер тапкыр (консультацияләрне исәпкә алмыйча), ә мөрәҗәгать итүче билгеләнгән тәртиптә расланган кирәкле барлык документларны тапшырган очракта берлектә эшләү зарурилыгы юк (консультацияләрне исәпкә алмыйча).<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең дәүләт | |

| | | |
|---|---|---|
| | хезмәте күрсәтүче белгеч белән бер тапкыр берлектә эшләү вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күп функцияле үзәге (алга таба – МФЦ), МФЦның ерактагы эш урыннары аша дәүләт хезмәте күрсәтелми.<br>Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүматлар белән ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе сайтында (http://gosalcogol.tatar.ru) Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) күрсәтүнең бердәм порталында таныша ала. | |
| 2.16. Дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Гариза һәм документлар (документлар күчермәләре) ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенә һәм аның территориаль бүлекләренә электрон имза белән имзаланган (расланган) электрон документлар рәвешендә җибәрелергә мөмкин. | №210-ФЗ Федераль закон;<br>№63-ФЗ Федераль закон |

**3. Административ процедуралар (гамәлләр) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада үтәү үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күп функцияле үзәкләрдә, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күп функцияле үзәкнең ерактагы эш урыннарында үтәү үзенчәлекләре**

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә гамәлләр эзлеклелегенең тасвирламасы.

3.1.1. Лицензия бирү, гамәлдә булу срогын озайту, яңадан рәсмиләштерү, гамәлдә булуын яңарту, лицензиянең гамәлдә булуын туктату буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү,

2) гариза һәм документларын кабул итү һәм теркәү;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара запрослар булдырып җибәрү;

4) лицензия бирү, яңадан рәсмиләштерү, гамәлә булуын яңарту, лицензиянең гамәлдә булуын туктату, лицензиянең гамәлдә булу срогын озайту, бирелгән лицензияне башкасына алыштыру турында боерык әзерләү һәм раслау;

5) лицензия бирүдән, яңадан рәсмиләштерү, гамәлә булуын яңарту, лицензиянең гамәлдә булуын туктату, лицензиянең гамәлдә булу срогын озайту, бирелгән лицензияне башкасына алыштырудан баш тарту турында боерык әзерләү һәм раслау;

6) техник хатаны төзәтү;

7) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы №17 кушымтада бирелә.

3.2. Мөрәҗәгать итүчегә консультацияләр бирү.

3.2.1. Мөрәҗәгать итүче лицензияләүче органга (алга таба – лицензияләү бүлеге) дәүләт хезмәте алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен шәхсән үзе, телефоннан һәм (яки) электрон почта аша мөрәҗәгать итүгә хокуклы.

Мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле гаризаның составы, формасы һәм эчтәлеге ягыннан, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны рәсмиләштерү ягыннан, мөрәҗәгать итүче телдән (шул исәптән телефон аша) мөрәҗәгать иткәндә, лицензияләү бүлеге белгече тарафыннан хәл ителә.

Лицензияләү бүлеге белгече мөрәҗәгать итүчегә консультация бирә, шул исәптән тапшырыла торган документларның составы, формасы буенча һәм дәүләт хезмәте алу өчен башка мәсьәләләр буенча.

Бу пунктта билгеләнелә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көне хәл ителә. Административ процедураның озынлыгы шәхсән мөрәҗәгать ителгәндә консультация башлангач 15 минуттан һәм телефон аша сөйләшү башлангач 10 минуттан артмаска тиеш.

Процедуралар нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы буенча һәм дәүләт хезмәте алуга кагылышлы башка мәсьәләләр буенча консультацияләр.

3.3. Алкогольле продукцияне ваклап сатуга һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия бирү.

3.3.1. Лицензиягә дәгъва кылучы шәхсән яки электрон рәвештә (электрон имза белән имзаланган (расланган) электрон документлар рәвешендә) яисә почта аша (тапшыру турында уведомление һәм конверт эчендәге документлар исемлеге белән) №16 кушымта нигезендә лицензияләүче органга юридик затны дәүләт теркәвенә алу урыны буенча лицензия бирү турында гариза (№5 кушымта) һәм бу Регламентның 2.5 пункты нигезендә документлар тапшыра.

Бирү турында гаризага лицензиягә дәгъва кылучы җитәкчесе яки ышанычнамә нигезендә эш итүче вәкаләтле зат кул куя.

Электрон рәвештә документлар тапшыру очрагында лицензияләү бүлеге белгече, дата һәм теркәү номерын күрсәтеп, электрон рәвештәге җавап хәбәре белән алу фактын арслый.

Электрон рәвештә җибәрелгән документлар «zip» яки «rar» форматында мәгълүматлар архивына тупланып, Portable Document Format (PDF) форматында сканлаштырылган рәвештә тапшырыла.

3.3.2. Лицензия бүлеге белгече:

- исемлек буенча документларны кабул итә;

- кулдан тапшырылган яки почта аша яисә электрон почта җибәрелгән гаризаны гаризаларны теркәү журналында терки (№12 кушымта);

- лицензиягә дәгъва кылучыга, гариза һәм документларны кабул итү датасы, керү номеры турында билге белән, документларның исемлеге күчермәсен тапшыра.

Бу пунктта билгеләнелә торган процедуралар гариза кергән көнне хәл ителә.

Процедуралар нәтиҗәсе: гаризаларны теркәү журналында теркәү язуын булдыру һәм документларны эшкә җибәрү.

3.3.3. Лицензияләү бүлеге белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша электрон рәвештә запрослар җибәрә:

- Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан мәгълүматлар тапшыру турында;

- Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрыннан мәгълүматлар тапшыру турында;

- Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә салымнар һәм җыемнар, салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законын бозган өчен пенялар һәм штрафлар түләү буенча мәгълүматлар тапшыру турында;

- Федераль казначылык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә дәүләт пошлинасын түләү турында мәгълүматлар тапшыру хакында;

- Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә Федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) буена идарәсенә эшмәкәрлек эшчәнлегенең аерым төрләрен хәл итүне башлап җибәрү (Россия буенча) турында уведомлениеләр реестрыннан мәгълүматлар тапшыру (техник мөмкинлек булганда) хакында.

Бу пунктта билгеләнелә торган процедуралар гариза кергән көнне хәл ит.

Процедуралар нәтиҗәсе: мәгълүматлар тапшыру турында запрослар.

3.3.4.Лицензияләү бүлеге белгече алынган документлар нигезендә:

лицензия эшен булдыра (аерым папкага туплый);

тапшырылган документларның закон таләпләренә туры килү-килмәвенә планнан тыш тикшерү үткәрә (тапшырылган документларның тулылыгын, дөреслеген һәм кирәклеген билгели), шул исәптән түбәндәгеләрне тикшерә:

- документларга мөһерләр куелу-куелмавын якларның яки билгеле бер вәкаләтле вазыйфаи затларның имзалары булу-булмавын;

-документларда чистарту-бетерү, сызу-бозуларның һәм аңлатылмаган төзәтүләрнең булу-булмавын.

Бүлек белгече планнан тыш документар тикшерү нәтиҗәләре буенча документар тикшерү акты һәм бәяләмә рәсмиләштерә.

Бу пунктчада билгеләнелә торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң дүрт эш көненнән дә күбрәк булмаган срокта хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: лицензия эшен, документар тикшерү актын, бәяләмә булдыру.

3.3.5.Документларга өстәмә экспертиза үткәрү кирәк булган очракта, лицензияләү бүлеге белгече:

документларга өстәмә экспертиза билгеләү зарурилыгы һәм гаризаны карап тикшерү срогын озайту зарурилыгы турында хезмәт язуын әзерли;

документларга өстәмә экспертиза үткәрү турында боерык проектын һәм лицензиягә дәгъва кылучы исеменә уведомление проектын әзерли;

лицензияләү бүлеге начальнигы виза салган әзер проектларны лицензияләүче орган җитәкчесенә имза салуга җибәрә.

Процедура нәтиҗәсе: документларга өстәмә экспертиза билгеләү һәм гаризаны карап тикшерү срогын озайту зарурилыгы турында хезмәт запискасы, боерык проекты һәм уведомление проекты.

3.3.6.Лицензияләүче орган җитәкчесе өстәмә экспертиза үткәрү турында карар кабул итә, документларга өстәмә экспертиза үткәрү турында боерыкка һәм уведомлениегә кул куя (уңай карар кабул ителгән очракта) һәм лицензияләү бүлеге белгеченә җибәрә.

Процедура нәтиҗәсе: өстәмә экспертиза үткәрү турында карар – имза салынган боерык һәм уведомление.

3.3.7.Лицензияләә бүлеге белгече лицензиягә дәгъва кылучыга тапшырылган документларына өстәмә экспертиза үткәрү зарурилыгына бәйле рәвештә гаризаны карап тикшерү срогын озайтырга кирәклеге турында уведомление җибәрә.

Бу Регламентның 3.3.5-3.3.6 пунктчаларында билгеләнелә торган процедуралар өстәмә экспертиза үткәрү турында карар кабул ителгәннән соң бер эш көне эчендә хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: документларга өстәмә экспертиза үткәрү турында уведомлениене мөрәҗәгать итүчегә җибәрү.

3.3.8.Лицензияләү бүлеге белгече, дөрес мәгълүматлар алу максатыннан чыгып, тиешле дәүләт органнарына запрослар җибәрә.

Бу пунктта билгеләнелә торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә хәл ителә .

Процедура нәтиҗәсе: запрослар җибәрү.

3.3.9.Лицензияләү бүлеге белгече алынган мәгълүматлар нигезендә:

-тапшырылган документларның алынган мәгълүматларга туры килү-килмәвенә анализ ясый;

-документларга өстәмә экспертиза үткәрә;

-бәяләмә әзерли.

Бу пунктчада билгеләнелә торган процедуралар алдагы процедура тәмамланганнан соң биш эш көне эчендә хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: бәяләмә.

3.3.10.Лицензия бирү турында гариза тапшырган лицензиягә дәгъва кылучыга яки лицензияне яңадан рәсмиләштерү яисә гамәлдә булу срогын озайту турында гариза тапшырган лицензиатка карата планнан тыш документар һәм планнан тыш күчмә тикшерүләр үткәрелә. Планнан тыш күчмә тикшерүләр үткәрүнең тәртибе Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең 24.11.2017 ел, №12-07/200 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең алкогольле һәм спиртлы продукцияне ваклап сату өлкәсендә төбәк дәүләт контрольлеген (күзәтчелек) хәл итү буенча дәүләт функциясен башкаруның административ регламентында билгеләнгән.

Процедура нәтиҗәсе: тикшерү акты.

3.3.11.Лицензияләү бүлеге белгече бәяләмә һәм тикшерүләр актлары нигезендә:

-лицензия бирү яки аны бирүдән баш тарту турында боерык проектын әзерли;

-лицензия бирү турында уведомление проектын (№9 кушымта) яки, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, боерыкка таянып, аны бирүдән баш тарту турында уведомление проектын әзерли;

-лицензияләү бүлеге начальнигы виза салган әзер проектларны лицензия эше белән бергә лицензияләүче орган җитәкчесенә килештерүгә җибәрә.

Бу пунктчада билгеләнелә торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң өч эш көне эчендә хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: лицензия бирү яки лицензия бирүдән баш тарту турында боерык проекты, лицензия бирү яки аны бирүдән баш тарту турында уведомление проекты һәм аларны җитәкчегә җибәрү.

3.3.12.Лицензияләүче орган җитәкчесе лицензия бирү турында боерыкка һәм лицензия бирү турында уведомлениегә яки лицензия бирүдән баш тарту турында боерыкка һәм лицензия бирүдән баш тарту турында уведомлениегә кул куя һәм лицензияләү бүлеге белгеченә җибәрә.

Бу пунктчада билгеләнелә торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: лицензия бирү турында яки аны бирүдән баш тарту турында имзаланган боерык һәм уведомление.

3.3.13. Лицензияләү бүлеге белгече:

лицензиягә дәгъва кылучыга лицензия бирү турында уведомление (№9 кушымта) яки, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, лицензия бирүдән баш тарту турында уведомление тапшыра (почта аша яки электрон почта аша җибәрә);

лицензия һәм аңа кушымталарны рәсмиләштерә;

лицензия турында мәгълүматларны ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенә мәгълүматлар базасына кертә;

лицензия һәм аңа кушымталарны лицензияләүче орган җитәкчесенә имза салуга җибәрә.

Бу пунктчада билгеләнелә торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң ике эш көне эчендә хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: лицензия бирү яки аны бирүдән баш тарту турында уведомление, лицензия һәм аңа кушымтаны бирү (җибәрү), җитәкчегә имза салуга җибәрү.

3.3.14.Лицензияләүче орган җитәкчесе лицензия һәм аңа кушымтага кул куя, мөһер белән раслый һәм лицензияләү бүлеге белгеченә җибәрә.

Бу пунктта билгеләнелә торган процедура документлар алынган көнне хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: лицензия һәм аңа кушымтага имза салу.

3.3.15.Лицензияләү бүлеге белгече мөрәҗәгать итүченең теләгенә карап алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия, җәмәгать туклануы

хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне бирә яки мөрәҗәгать итүчегә мондый лицензия бирүдән баш тарту турында уведомлениене мөрәҗәгать итүченең кулына тапшыра яисә, тапшыру турында уведомление белән, почта аша заказлы хат белән җибәрә. Документларны электрон рәвештә тапшыру очрагында лицензия бирү кәгазь документлар күрсәтелгәннән соң хәл ителә.

Лицензия һәм аңа кушымтаны бирү факты лицензияләр бирүне теркәү журналында (№13 кушымта) теркәүгә алына.

Бу пунктта билгеләнелә торган процедура лицензиягә дәгъва кылучы килгән көнне хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: тапшырылган лицензия һәм аңа кушымта.

Лицензияләр бланкларының учет сериясе, номеры була һәм алар катгый хисап документлары булып тора. Лицензиягә лицензияләүче орган җитәкчесе һәм вәкаләтле зат имза сала һәм мөһер белән раслана.

Лицензиягә кушымта катгый хисап бланкында рәсмиләштерелә һәм лицензиянең аерылгысыз өлеше булып тора, аңа лицензияләүче орган җитәкчесе яки вәкаләтле зат кул куя һәм мөһер белән раслана.

3.3.16.Лицензияләү бүлеге белгече:

Лицензия бирү турында мәгълүматларны лицензияләр реестрына (№14 кушымта) кертә.

Бирелгән лицензия һәм аңа кушымтаның күчермәләрен лицензия эше материаллары янына туплап куя.

Бу пунктчада билгеләнелә торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең мәгълүматлар базасына кертелгән, бирелгән лицензия турында мәгълүматлар.

3.4.Алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне, җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне яңадан рәсмиләштерү

3.4.1.Лицензиат шәхсән үзе, электрон почта аша (электрон имза белән имзаланган (расланган) электрон документлар рәвешендә) яки почта аша (тапшыру турында уведомление һәм конверт эчендәге документлар исемлеге белән, кыйммәтле хат рәвешендә) лицензияләүче органга лицензияне яңадан рәсмиләштерү турында гариза (№7 кушымта) тапшыра (җибәрә) һәм бу Регламентның 2.5 пункты нигезендә документлар тапшыра.

Электрон рәвештә документлар тапшыру очрагында лицензияләү бүлеге белгече, дата һәм теркәү номерын күрсәтеп, электрон рәвештә җавап хәбәре белән документларны алганлыкны раслый.

Электрон рәвештә җибәрелгән документлар «zip» яки «rar» форматында мәгълүматлар архивына тупланып, Portable Document Format (PDF) форматында сканлаштырылган рәвештә тапшырыла.

Оешма үзгәртеп оештырылган очракта (юридик затларның кушылу рәвешендә үзгәртеп оештырылуыннан тыш һәм үзгәртеп оештырылган

юридик затларның хокукый дәвамчысын дәүләт теркәвенә алу датасына юридик затларның һәркайсының алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензиясе булган очрактан тыш) лицензияне яңадан рәсмиләштерү бу Регламентның 3.3.2-3.3.16 пунктчаларында билгеләнгән тәртиптә хәл ителә.

Лицензиатның атамасы үзгәртелгән очракта (үзгәртеп оештырылмаган килеш кенә), аның урнашу урыны яки лицензиядә күрсәтелгән аерымланган подразделениеләренең урнашу урыннары, эшчәнлекнең лицензияләнелә торган төрен хәл кылу өчен файдаланыла торган стационар сәүдә объектының аренда срогы тәмамлануы, сәүдә объектларын ачу һәм ябу срогы үзгәргән очракта, лицензиядә күрсәтелгән башка мәгълүматлар үзгәртелгәндә, шулай ук лицензия югалтылган очракта бу Регламентның 3.4.2-3.4.9 пунктчаларында күздә тотылган процедуралар хәл ителә.

3.4.2.Лицензияне яңадан рәсмиләштерү турында гариза кабул итү һәм теркәү бу Регламентның 3.3.2 пунктчасы нигезендә хәл ителә.

3.4.3.Тапшырылган документларга гамәлдәге закон таләпләренә туры килү-килмәүләренә экспертиза үткәрү (тапшырылган документларның дөреслеген, тулылыгын һәм тиешлеген билгеләүне үз эченә алган) бу Регламентның 3.3.3 һәм 3.3.4. пунктчалары нигезендә хәл ителә.

3.4.4. Лицензияләү бүлеге белгече документларга экспертиза (бу Регламентның 3.3.4 п.) һәм бу Регламентның 3.3.10 п. нигезләмәләренә туры китереп әзерләнгән тикшерү актына экспертиза нигезендә:

лицензияне яңадан рәсмиләштерү яки яңадан рәсмиләштерүдән баш тарту турында боерык проекты әзерли;

яңадан рәсмиләштерү турында уведомление проектын (№ 9 кушымта яки баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, боерыкка таянып, яңадан рәсмиләштерүдән баш тарту турында уведомление проекты әзерли;

лицензияләү бүлеге начальнигы виза салган документлар проектларын лицензияләүче орган җитәкчесенә имза салуга җибәрә.

Бу пунктчада билгеләнелә торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң ике эш көне эчендә хәл ителә.

Процедуралар нәтиҗәсе: лицензияне яңадан рәсмиләштерү яки аны яңадан рәсмиләштерүдән баш тарту турында боерык проекты, лицензияне яңадан рәсмиләштерү яки аны яңадан рәсмиләштерүдән баш тарту турында уведомление проекты.

3.4.5.Лицензияләүче орган җитәкчесе лицензияне яңадан рәсмиләштерү турында боерыкка һәм лицензияне яңадан рәсмиләштерү турында уведомлениегә яки лицензияне яңадан рәсмиләштерүдән баш тарту турында боерыкка һәм уведомлениегә кул куя һәм лицензияләү буенча белгечкә җибәрә.

Бу пунктчада билгеләнелә торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: лицензияне яңадан рәсмиләштерү яки аны яңадан аны яңадан рәсмиләштерүдән баш тарту турында имзаланган боерык һәм лицензияне яңадан рәсмиләштерү турында яисә аны рәсмиләштерүдән баш тарту турында имзаланган уведомление.

3.4.6.Лицензияләү бүлеге белгече:

Лицензиатка лицензияне яңадан рәсмиләштерү турында яки, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, аны рәсмиләштерүдән баш тарту турында уведомление җибәрә (почта аша яки электрон почта аша);

алдагы лицензиядә күрсәтелгән гамәлдә булу срогын саклап, лицензияне һәм аңа кушымтаны яңадан рәсмиләштерә;

яңадан рәсмиләштерелгән лицензия турында мәгълүматларны ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең мәгълүматлар базасына кертә;

яңадан рәсмиләштерелгән лицензия һәм аңа кушымтаны лицензияләүче орган җитәкчесенә имза салуга җибәрә.

Бу пунктчада билгеләнелә торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң ике эш көне эчендә хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: лицензияне яңадан рәсмиләштерү яки аны яңадан рәсмиләштерүдән баш тарту турында бирелгән (җибәрелгән) уведомление, яңадан рәсмиләштерелеп, җитәкчегә имза салуга җибәрелгән лицензия һәм (яки) аңа кушымта, мәгълүматлар базасына кертелгән мәгълүматлар.

3.4.7.Лицензияләүче орган җитәкчесе яңадан рәсмиләштерелгән лицензиягә һәм (яки) кушымтага имза сала, мөһер белән раслый һәм лицензияләү буенча белгечкә җибәрә.

Бу пунктчада билгеләнелә торган процедура документлар алынган көнне хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: яңадан рәсмиләштерелгән лицензиягә һәм (яки) аңа кушымтага имза салу.

3.4.8.Лицензияләү бүлеге белгече мөрәҗәгать итүченең теләгенә карап алкогольле продукцияне ваклап сатуга яңадан рәсмиләштерелгән лицензияне, җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга яңадан рәсмиләштерелгән лицензияне яки мондый лицензия тапшырудан баш тарту турында уведомлениене мөрәҗәгать итүченең шәхсән кулына тапшыра яки почта аша заказлы хат белән (тапшыру турында уведомление белән) җибәрә. Электрон рәвештә документлар тапшыру очрагында яңадан рәсмиләштерелгән лицензияне бирү кәгазь документлар күрсәтелгәннән соң хәл ителә .

Яңадан рәсмиләштерелгән лицензия һәм аңа кушымталарны бирү факты лицензияләр бирүне теркәү журналында (№13 кушымта) теркәүгә алына.

Лицензия яңадан рәсмиләштерелгәнче, оешма яки аның хокукый дәвамчысы элегрәк бирелгән лицензия нигезендә эшчәнлекне алып барырга мөмкин.

Бу пунктчада билгеләнелә торган процедура лицензиат килгән көнне хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: яңадан рәсмиләштерелгән лицензия һәм (яки) аңа кушымтаны бирү.

3.4.9.Лицензияләү буенча белгеч:

Яңадан рәсмиләштерелгән лицензия турында мәгълүматларны лицензияләр реестрына кертә;

Яңадан рәсмиләштерелгән лицензиат һәм (яки) аңа кушымта күчермәләрен лицензия эше материаллары янына туплап куя.

Бу пунктчада билгеләнелә торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: яңадан рәсмиләштерелгән лицензия турында мәгълүматларны лицензияләр реестрына кертү.

3.5.Алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия срогын, җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензия срогын озайту

3.5.1.Лицензиат шәхсән яки электрон почта аша (электрон имза белән имзаланган (расланган) электрон документлар рәвешендә) яки почта аша (тапшыру турында уведомление һәм конвертка салынган документлар исемлеге белән, почта аша кыйммәтле хат рәвешендә) лицензияләүче органга лицензиясенең гамәлдә булу срогын озайту турында гариза (№6 кушымта) тапшыра (җибәрә) һәм бу Регламентның 2.5 пункты нигезендә документлар тапшыра.

Документлар электрон рәвештә тапшырылган очракта лицензияләү бүлеге белгече, дата һәм теркәү номерын күрсәтеп, электрон рәвештә җавап хәбәре белән документлар алганлыкны раслый.

Электрон рәвештә җибәрелгән документлар «zip» яки «rar» форматында мәгълүматлар архивына тупланып, Portable Document Format (PDF) форматында сканлаштырылган рәвештә тапшырыла.

3.5.2. Лицензиянең гамәлдә булу срогын озайту турында гаризаны кабул итү һәм теркәү бу Регламентның 3.3.2 пунктчасы нигезендә хәл ителә.

3.5.3. Тапшырылган документларга гамәлдәге закон таләпләренә туры килү-килмәүләренә экспертиза үткәрү (тапшырылган документларның дөреслеген, тулылыгын һәм тиешлеген билгеләүне үз эченә алган) бу Регламентның 3.3.3 һәм 3.3.4. пунктчалары нигезендә хәл ителә.

3.5.4. Лицензияләү бүлеге белгече документларга экспертиза (бу Регламентның 3.3.1 п.) һәм бу Регламентның 3.3.10 п. нигезләмәләренә туры китереп әзерләнгән тикшерү актына экспертиза нигезендә:

лицензиянең гамәлдә булу срогын озайту яки лицензиянең гамәлдә булу срогын озайтудан баш тарту турында боерык проекты әзерли;

лицензиянең гамәлдә булу срогын озайту турында уведомление проектын (№ 9 кушымта), яки баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, боерыкка таянып, аны озайтудан баш тарту турында уведомление проекты әзерли;

лицензияләү бүлеге начальнигы виза салган документлар проектларын лицензияләүче орган җитәкчесенә имза салуга җибәрә.

Бу пунктта билгеләнелә торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң ике эш көне эчендә хәл ителә.

Процедуралар нәтиҗәсе: лицензиянең гамәлдә булу срогын озайту яки лицензиянең гамәлдә булу срогын озайтудан баш тарту турында боерык проектын һәм уведомление проектын лицензияләүче орган җитәкчесенә имза салуга җибәрү.

3.5.5.Лицензияләүче орган җитәкчесе лицензиянең гамәлдә булу срогын озайту яки лицензиянең гамәлдә булу срогын озайтудан баш тарту турында боерыкны, лицензиянең гамәлдә булу срогын озайту турында яки лицензиянең гамәлдә булу срогын озайтудан баш тарту турында уведомлениегә имза сала һәм лицензияләү бүлеге белгеченә җибәрә.

Бу пунктта билгеләнелә торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: боерык һәм уведомлениегә имза салу.

3.5.6.Лицензияләү бүлеге белгече:

лицензиатка лицензиянең гамәлдә булу срогын озайту яки лицензиянең гамәлдә булу срогын озайтудан баш тарту турында, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, уведомление тапшыра (почта яки электрон почта аша җибәрә);

лицензиянең гамәлдә булу срогын озайту турында мәгълүматларны ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең мәгълүматлар базасына кертә.

Лицензияләү буенча белгеч элегрәк гамәлдә булган лицензиянең төп нөсхәсендә "озайту" графасына лицензиянең күпмегә озайтылуын күрсәтә һәм аның лицензияләүче орган җитәкчесенә имза салуга җибәрә.

Бу пунктта билгеләнелә торган процедуралар алдагы процедура тәмамланганнан соң ике эш көне эчендә хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: лицензиянең гамәлдә булу срогын озайту яки лицензиянең гамәлдә булу срогын озайтудан баш тарту турында бирелгән (җибәрелгән) уведомление, озайту срогы куелган лицензия, лицензияләүче орган җитәкчесенә имза салуга җибәрелгән.

3.5.7.Лицензияләүче орган җитәкчесе лицензиягә кул куя, мөһер белән раслый һәм лицензияләү буенча белгечкә җибәрә.

Бу пунктта билгеләнелә торган процедура документлар алынган көнне хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: имзаланган лицензия.

3.5.8.Лицензияләү бүлеге белгече мөрәҗәгать итүченең теләгенә карап алкогольле продукцияне ваклап сатуга гамәлдә булу срогы озайтылган лицензия, җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга гамәлдә булу срогы озайтылган лицензия тапшыра. Электрон рәвештә документлар тапшыру очрагында яңадан рәсмиләштерелгән лицензияне бирү кәгазь документлар күрсәтелгәннән соң хәл ителә.

Лицензия һәм аңа кушымталарны бирү факты лицензияләр бирүне теркәү журналында (№13 кушымта) теркәүгә алына.

Бу пунктта билгеләнелә торган процедура лицензиат килгән көнне хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: озайтылган лицензияне һәм аңа кушымтаны бирү.

3.5.9.Лицензияләү бүлеге белгече: лицензиянең гамәлдә булу срогын озайту турында мәгълүматларны лицензияләр реестрына кертә;

Озайтылган лицензия һәм аңа кушымта күчермәләрен лицензия эше материаллары янына туплап куя.

Бу пунктта билгеләнелә торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: озайтылган лицензия бирү турында мәгълүматларны лицензияләр реестрына кертү.

3.6. Бирү (лицензия срогын озату, лицензияне яңадан рәсмиләштерү) турында гаризаны кире алу

3.6.1.Мөрәҗәгать итүче лицензияләүче органга шәхсән үзе яки почта аша (тапшыру турында уведомление һәм конверт эчендәге документлар исемлеге белән кыйммәтле хат рәвешендә) яисә электрон почта аша бирү (лицензия срогын озату, лицензияне яңадан рәсмиләштерү) турында гаризаны кире алу турында ирекле формада гариза язып тапшыруга хокуклы.

Гариза электрон рәвештә тапшырылган очракта лицензияләү бүлеге белгече, дата һәм теркәү номерын күрсәтеп, электрон рәвештә җавап хәбәре рәвешендә документларны алганлыкны раслый.

Электрон рәвештә җибәрелгән документлар «zip» яки «rar» форматында мәгълүматлар архивына тупланып, Portable Document Format (PDF) форматында сканлаштырылган рәвештә тапшырыла.

3.6.2.Гаризаны кабул итү һәм теркәү бу Регламентның 3.3.2 пунктчасы нигезендә (№12 кушымта) хәл ителә.

Лицензияләү бүлеге белгече:

бирү (лицензия срогын озату, лицензияне яңадан рәсмиләштерү) турында гаризаны карап тикшерү процедурасын туктату турында боерык проектын әзерли;

гаризаны карап тикшерү процедурасын туктату турында уведомление проектын әзерли;

лицензияләү бүлеге начальнигы виза салган документлар проектларын лицензияләүче орган җитәкчесенә имза салуга җибәрә.

Бу пунктта билгеләнелә торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: боерык проекты.

3.6.4.Лицензияләүче орган җитәкчесе бирү (лицензия срогын озату, лицензияне яңадан рәсмиләштерү) турында гаризаны карап тикшерү процедурасын туктату турында боерыкка һәм уведомлениегә имза сала һәм лицензияләү бүлеге белгеченә җибәрә.

Бу пунктта билгеләнелә торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: имзаланган боерык һәм уведомление.

3.6.5.Лицензияләү бүлеге белгече мөрәҗәгать итүчегә почта яки электрон почта аша уведомление җибәрә.

Бу пунктта билгеләнелә торган процедура лицензияләүче орган җитәкчесе боерыкка имза салган көнне хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: уведомление җибәрү.

3.6.7.Лицензияләү бүлеге белгече мөрәҗәгать итүчегә бирү (лицензия срогын озату, лицензияне яңадан рәсмиләштерү) турында гаризасы белән бергә лицензияләүче органга тапшырылган документларын кире кайтара. Гаризага документлар исемлегендә документларны мөрәҗәгать итүчегә кире кайтару турында язып куела.

Бу пунктта билгеләнелә торган процедура мөрәҗәгать итүче килгән көнне хәл ителә .

3.7. Алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензиянең, җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензиянең гамәлдә булуын яңарту

3.7.1.Лицензиат лицензиясенең гамәлдә булуын яңарту өчен лицензияләүче органга шәхсән яки почта (тапшыру турында уведомление һәм конверттагы документларны исемлеге белән, кыйммәтле хат рәвешендә) яисә электрон почта аша, бу Регламентның 2.5 пункты таләпләре нигезендә, нигезләү документлары белән бергә, лицензиянең гамәлдә булуын туктатып торуга китергән хәлләрнең юкка чыгарылу сәбәпле аны яңарту турында гариза тапшыра.

Электрон рәвештә гариза тапшыру очрагында лицензияләү бүлеге белгече, датасын һәм теркәү номерын күрсәтеп, электрон рәвештә җавап хәбәре нигезендә документларның алынганлыгын раслый.

Электрон рәвештә җибәрелгән документлар «zip» яки «rar» форматында мәгълүматлар архивына тупланып, Portable Document Format (PDF) форматында сканлаштырылган рәвештә тапшырыла.

3.7.2.Лицензиянең гамәлдә булуын яңарту турындагы гаризаны кабул итү һәм теркәү бу Регламентның 3.3.2 пунктчасы нигезендә хәл ителә.

3.7.3.Лицензияләү буенча белгеч:

лицензиат тарафыннан лицензиясенең гамәлдә булу шартларын бозуларны юкка чыгару фактын раслау максатыннан чыгып, планнан тыш тикшерү үткәрә;

лицензиягә кушымталарда күрсәтелгән сәүдә объектларында алкогольле продукция калдыкларын алу актын рәсмиләштерә һәм лицензиянең гамәлдә булуын туктатып тору вакытына алкогольле продукция калдыкларының туры килү-килмәвен билгели.

Бу пунктчада билгеләнелә торган процедуралар алдагы процедура тәмамланганнан соң өч эш көне эчендә хәл ителә.

Процедуралар нәтиҗәсе: лицензиатның сәүдә объектында (сәүдә объектларында алкогольле продукция калдыкларын алу турында

рәсмиләштерелгән акт һәм лицензиянең гамәлдә булу шартларын бозуларны юкка чыгару фактын раслау).

3.7.4.Лицензияләү буенча белгеч тапшырылган документлар һәм лицензиягә кушымтада күрсәтелгән сәүдә объектларында алкогольле продукция калдыкларын алу акты нигезендә:

лицензиянең гамәлдә булуын яңарту яки яңартудан баш тарту турында боерык проектын әзерли;

лицензиянең гамәлдә булуын яңарту яки, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, боерыкка таныл, лицензиянең гамәлдә булуын яңартудан баш тарту турында уведомление проектын әзерли;

лицензияләү бүлеге начальнигы имза салган уведомление һәм боерык проектын лицензияләүче орган җитәкчесенә имза салуга җибәрә.

Бу пунктчада билгеләнелә торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә хәл ителә.

Процедуралар нәтиҗәсе: лицензиянең гамәлдә булуын яңарту яки яңартудан баш тарту турында боерык һәм уведомление проектларын лицензияләүче орган җитәкчесенә имза салуга җибәрү.

3.7.5.Лицензияләүче орган җитәкчесе лицензиянең гамәлдә булуын яңарту лицензиянең гамәлдә булуын яңартудан баш тарту турында боерык һәм уведомление проектын имзалый һәм лицензияләү бүлеге белгеченә җибәрә.

Бу пунктта билгеләнелә торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: лицензиянең гамәлдә булуын яңарту яки лицензиянең гамәлдә булуын яңартудан баш тарту турында имзаланган боерык һәм уведомление.

3.7.6. Лицензияләү бүлеге белгече:

лицензиянең гамәлдә булуын яңарту яки лицензиянең гамәлдә булуын яңартудан баш тарту турында мәгълүматларны ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең мәгълүматлар базасына кертә;

лицензиянең гамәлдә булуын яңарту (№11 кушымта) яки, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, лицензиянең гамәлдә булуын яңартудан баш тарту турында уведомление бирә (почта аша яки электрон почта аша җибәрә).

Лицензиянең гамәлдә булуын яңарту турында мәгълүматлар ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең рәсми сайтына урнаштырыла.

Бу пунктта билгеләнелә торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң өч эш көне эчендә хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: лицензиатка лицензиянең гамәлдә булуын яңарту турында бирелгән (җибәрелгән) уведомление хакында мәгълүматларны мәгълүматлар базасына кертү.

3.8. Лицензиат гаризасы нигезендә лицензиянең гамәлдә булуын туктату

3.8.1. Лицензиянең гамәлдә булуын туктату, лицензия белән бергә, эшчәнлекнең лицензияләнелә торган төрен хәл кылуны туктату турында лицензиатның язмача гариза тапшыруы нигезендә хәл ителә.

3.8.2. Лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында гаризаны кабул итү һәм теркәү бу Регламентның 3.3.2 пунктчасы нигезендә хәл ителә.

3.8.3. Лицензияләү бүлеге белгече:

лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында боерык проектын әзерли;

лицензиянең гамәлдә булуын туктату уведомление проектын әзерли;

лицензияләү бүлеге начальнигы виза салган боерык һәм уведомление проектын лицензияләүче орган җитәкчесенә имза салуга җибәрә.

Бу пунктта билгеләнелә торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң җиде эш көне эчендә хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында боерык һәм уведомление проекты.

3.8.4. Лицензияләүче орган җитәкчесе лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында боерыкны һәм уведомлениене имзалый һәм лицензияләү бүлеге белгеченә җибәрә.

Бу пунктта билгеләнелә торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында имзаланган боерык һәм уведомление.

3.8.5. Лицензияләү бүлеге белгече лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында мәгълүматларны ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең мәгълүматлар базасына кертә һәм лицензиатка лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында уведомление бирә (почта аша җибәрә).

Лицензияләү бүлеге белгече лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында мәгълүматларны ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең мәгълүматлар базасына, лицензияләр реестрына кертә һәм ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең рәсми сайтына урнаштыра.

Бу пунктта билгеләнелә торган процедуралар алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә хәл ителә.

Процедуралар нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә уведомление җибәрү, лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында мәгълүматларны ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең мәгълүматлар базасына урнаштыру, ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең рәсми сайтына урнаштыру.

Лицензиянең гамәлдә булуын туктату датасы булып лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында боерыкны имзалау датасы тора.

Лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында боерык лицензиягә кушымтада күрсәтелгән барлык сәүдә объектларында алкогольле продукция калдыгын , аны сатуга юл куймас өчен, өч эш көне эчендә алуга нигез булып тора.

3.9. Рәсмиләштерелгәндә техник хата җибәрелүгә бәйле рәвештә бирелгән лицензияне һәм аңа кушымталарны алыштыру.

3.9.1. Лицензияләүче орган техник хата барлыгын ачыклаганда, бирелгән лицензияне һәм аңа кушымталарны алыштыру.

3.9.2. Лицензияләү бүлеге белгече техник хата ачыкланган очракта

доклад язуын әзерли, лицензияләү бүлеге начальнигыннан виза салдыра һәм аны лицензияләүче орган җитәкчесенә тиешле аңлатма белән җибәрә.

Бу пунктта билгеләнелә торган процедура техник хата ачыкланган көнне хәл ителә.

Процедуралар нәтиҗәсе: лицензияләүче орган җитәкчесенә доклад язуы җибәрү.

3.9.3. Лицензияләүче орган җитәкчесе бирелгән лицензияне алыштыру турында карар кабул итә һәм лицензияләү бүлегенә белгеч кабул иткән карар турында хәбәр җиткерә.

Процедура нәтиҗәсе: бирелгән лицензияне алыштыру турында карар.

3.9.4. Лицензияләү бүлеге белгече:

бирелгән лицензияне һәм аңа кушымталарны алыштыру турында боерык проектын әзерли;

бирелгән лицензияне һәм аңа кушымталарны алыштыру турында уведомление проектын (№10 кушымта) әзерли;

лицензияләү бүлеге җитәкчесе виза салган боерык проектын һәм уведомление проектын лицензияләүче орган җитәкчесенә имза салуга җибәрә.

Процедура нәтиҗәсе: боерык проекты һәм уведмоление проекты.

3.9.5. Лицензияләүче орган җитәкчесе:

бирелгән лицензия һәм аңа кушымтаны алыштыру турында боерыкка кул куя;

бирелгән лицензия һәм аңа кушымтаны алыштыру турында уведомлениегә кул куя;

боерык һәм уведомлениене лицензияләү бүлеге белгеченә җибәрә.

Процедура нәтиҗәсе: лицензияләүче орган җитәкчесе кул куйган, бирелгән лицензия һәм аңа кушымтаны алыштыру турында боерык һәм уведомление.

3.9.6. Лицензияләү бүлеге белгече лицензиатка бирелгән лицензия һәм аңа кушымтаны алыштыру турында уведомление җибәрә.

Бу Регламентның 3.9.2 – 3.9.5пунктчаларында билгеләнелә торган процедуралар алдагы процедура тәмамланганнан соң ике эш көне эчендә хәл ителә.

Процедуралар нәтиҗәсе: бирелгән лицензия һәм аңа кушымтаны алыштыру турында лицензиат исеменә уведомление җибәрү.

3.9.7. Лицензияләү бүлеге белгече:

лицензия һәм аңа кушымтаны рәсмиләштерә (анда лицензиянең гамәлдән чыгу срогы алыштырыла торган лицензиянең гамәлдән чыгу срогына туры килергә тиеш);

бирелгән лицензияне алыштыру турында ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең мәгълүматлар базасына мәгълүматлар кертә;

рәсмиләштерелгән лицензия һәм аңа кушымтаны алицензияләүче орган җитәкчесенә имза салуга җибәрә.

Бу пунктта билгеләнелә торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: рәсмиләштерелгән лицензия һәм бирелгән лицензия һәм аңа кушымтаны алыштыру турында лицензияләр реестрына кертелгән үзгәрешләр.

3.9.8. Лицензияләүче орган җитәкчесе рәсмиләштерелгән лицензия һәм аңа кушымтага имза сала, мөһер белән раслый һәм лицензияләү буенча белгечкә җибәрә.

Бу пунктта билгеләнелә торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: имзаланган лицензия һәм аңа кушымта

3.9.9. Лицензияләү буенча белгеч, алыштырыла торган лицензия һәм аңа кушымтаның төп нөсхәсен лицензияләүче органга кире кайтарылу шарты белән, лицензиатка яки ышанычлысына (ышанычнамәсе булганда) алыштырылган лицензияне бирә.

Бирү факты лицензияләр бирүне теркәү журналында теркәүгә алына. Лицензия һәм аңа кушымтаның күчермәләре лицензия эше материаллары янына туплап куела.

Бу пунктта билгеләнелә торган процедура лицензиат яки ышанычлысы килгән көнне хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: бирелгән лицензия һәм аңа кушымта.

3.9.10. Лицензиат лицензиясендә техник хатаның булуын ачыклаган очракта лицензияләүче органга бирелгән лицензия һәм аңа кушымтаны алыштыру турында ирекле формада язылган гариза тапшыра.

Лицензия һәм аңа кушымтаны алыштыру, лицензия һәм аңа кушымтаны бирү бу Регламентның 3.9.3 – 3.9.9 пунктлары нигезендә хәл ителә.

3.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күп функцияле үзәкләре, күп функцияле үзәкләрнең ерактагы эш урыннары аша хәл ителми.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә контрольлек итү тәртибе һәм формалары

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгы һәм сыйфатына контрольлек итү тикшерүләр үткәрүне, дәүләт хезмәте күрсәтүгә җаваплы вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмау) шикаятьләрдән торган мөрәҗәгатьләрне карап тикшерүне, карарлар кабул итүне һәм җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлүенә контрольлек формалары булып:

- делопроизводствоны алып баруга;

- документларны карап тикшерү нәтиҗәләренең законнар (бу Регламент) таләпләренә туры килүенә;

- документларны кабул итү сроклары һәм тәртибе үтәлүгә;

- дәүләт хезмәте күрсәткәндә нәтиҗәләрне бирү сроклары һәм тәртибе үтәлүгә тикшерүләр үткәрү тора.

Тикшерүләр уздыруның ешлыгы планлы (эш планнары нигезендә) һәм планнан тыш (мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча) була.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеген үтәүгә агымдагы контрольлекне ТР Дәүләт алкоголь җитәкчесе урынбасары һәм лицензияләүне хәл итүче бүлек начальнигы хәл кыла.

4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә контрольлекне ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесе хәл итә.

4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә гражданнар, аларның берләшмәләре, оешмалары тарафыннан контрольлек итү Үзәк бүлеге эшчәнлегенең дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыклыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карап тикшерү мөмкинлеге ярдәмендә башкарыла.

4.5. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча дәүләт хезмәте алганда гражданнарның хокукларын бозу ачыкланган очракта гаепле затлар Россия Федерациясе законы нигезендә җаваплылыкка тартыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең, шулай ук аның вазыйфаи затларының яки дәүләт хезмәткәрләренең карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр түбәндәгеләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауга) судка кадәр тәртиптә шикаять белдерүгә хокуклы:

бүлек белгече буенча – ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесенә;

ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесе тарафыннан кабул ителгән карарларга карата шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына белдерелергә мөмкин.

5.2. Гариза бирүче шикаять белән мөрәҗәгать итә ала, шул исәптән түбәндәге очракларда:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирүченең рәсми мөрәҗәгатен теркәү срогы бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү срогы бозылганда;

3) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган документлар таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылган документларны гариза бирүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) әгәр баш тартуга нигезләр федераль законнар һәм Россия Федерациясенең алар нигезендә кабул ителгән башка норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары нигезендә күздә тотылмаса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда;

6) дәүләт хезмәте яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган түләү таләп иткәндә;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче Үзәк бүлеге, шулай ук аның вазыйфаи заты, хезмәткәрләре дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартканда яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозганда.

5.3. Шикаять язмача кәгазьдә яки электрон рәвештә тапшырыла.

Шикаять почта аша, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең рәсми сайтыннан (https:// gosalcogol.tatar.ru.), Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталыннан (http://uslugi.tatar.ru), Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru) файдаланып җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул итү барышында кабул ителергә мөмкин.

5.4. Шикаятьне карап тикшерү срогы – аны теркәүгә алганнан соң унбиш эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, шулай ук аның вазыйфаи затының мөрәҗәгать итүчедән документларын кабул итеп алудан яисә җибәрелгән ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына карата шикаять белдерү очрагында яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозуга карата шикаять белдерү очрагында – аны теркәүгә алганнан соң биш эш көне эчендә.

5.5. Шикаять түбәндәге мәгълүматлардан торырга тиеш:

1) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның атамасы, шулай ук карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә карата шикаять белдерелә торган вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәрләренең исеме;

